СОВЕТ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** с.Старое Дрожжаное **КАРАР**

2019 елның 23 октябре № 38/7

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Советы Регламентына үзгәреш
кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Уставының 29 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советының 2005 елның 21 декабрендәге 2 номерлы Карары (2014 елның 9 апрелендәге 40/1 номерлы редакциясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Советы Регламентының «район Советының эш тәртибе» 5 нче бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 26.1 статья өстәп, үзгәреш кертергә:

«**26.1 Статья**

1. Гражданнар (физик затлар), шул исәптән оешмалар (Юридик затлар), иҗтимагый берләшмәләр, дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары (алга таба – гражданнар һәм оешмалар вәкилләре), түбәндәге очраклардан тыш, район Советы утырышында катнашу хокукына ия:

1) ябык утырыш уздыру;

2) керүе чикләнгән мәгълүматка караган мәгълүматларны утырышта карау;

3) эшчәнлеген тәэмин итү буенча оештыру-техник шартлар булмау.

2. Район Советы утырышы турында гражданнарга һәм оешма вәкилләренә хәбәр итү максатыннан, утырышка кадәр биш көннән дә соңга калмыйча район Советы утырышының көн тәртибе проекты «Туган як» газетасында басылып чыга, анда карала торган мәсьәләләрнең исеме һәм район Советы утырышын үткәрү вакыты күрсәтелә.

3. Район Советы утырышын уздыру вакытында гражданнарның һәм оешма вәкилләренең булу мөмкинлеге санитар нормаларны һәм кагыйдәләрне үтәүдән, залда буш утырту урыннары булудан чыгып билгеләнә

4. Гражданнар һәм оешма вәкилләре Совет утырышы башланганчы, телефон аша чакырылучыларны теркәүне гамәлгә ашыручы оештыру бүлеге хезмәткәрләренә, район Советы утырышына килүләре турында хәбәр итәргә тиешләр

5. Утырыш залында гражданнарны һәм оешма вәкилләрен урнаштыру, шулай ук аларның тәртибе оештыру бүлеге хезмәткәрләре тарафыннан тәэмин ителә.

6. Район Советы утырышын үткәрү вакытында залда утыручы гражданнар һәм оешмаларның вәкилләре җәмәгать урыннарында үз-үзеңне тоту буенча билгеләнгән нормаларны үтәргә бурычлы. Аларны бозган очракта гражданнар һәм оешмавәкилләре залдан чыгарылырга мөмкин, аларга Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарында каралган йогынты чаралары кулланылырга мөмкин.».

2. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль
районы башлыгы, Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы Советы Рәисе: М.Р. Гафаров